КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 18 май г.Казань № 706

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын яисә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм алып китү өчен мәйданчыкларны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 12 май, 310 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын яисә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм алып китү өчен мәйданчыкларны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 12 май, 310 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү системаларын яисә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм алып китү өчен мәйданчыкларны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнар өлешен финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктта «Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга «, Министрлыкка субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен җиткергән көннең иртәгесеннән соң 10 эш көне дәвамында» сүзләрен өстәргә;

55 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

62 пунктта «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин